**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**Старосляковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Иске Эсләк авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2022 Иске Эсләк № 20-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәклеге булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясен куллануны үзгәртү күздә тотылмавына, социаль-икътисадый үсешнең расланган программасы булмавына, Татарстан Республикасын һәм Әгерҗе муниципаль районын территориаль планлаштыру схемаларында федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмавына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең 2022 елның 30 декабренә кадәр генераль планны эшләү кирәк булмавын танырга.

Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Д.М. Әхмәтов